ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:
а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны раслау;»;
б) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 статьяда:
а) беренче абзацта «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы» сүзләрен «1. Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы» сүзләренә алмаштырырга;
б) 5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;
в) түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:
«16) коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативлары составына, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативларын билгеләү шартларына һәм алымнарына карата таләпләрне, шулай ук коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалануның билгеләнгән нормативы күләменең нигезләнгән булуын үтәүгә.»;

3) 6 статьяның 4 пунктында «гомумйорт ихтыяҗлары өчен коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын» сүзләрен «күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту максатларында салкын судан, кайнар судан файдалану, агып китүче

суларны җибәрү, электр энергиясеннән файдалану нормативларын» сүзләренә алмаштырырга;

4) 9 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 05 апрель
№ 15-ТРЗ